Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2023 ел № 83

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 01 ноябрендәге 25 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

Яңа Кәшер авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 01 ноябрендәге 25 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының 2023 елның 20 февралендәге 63 номерлы, 2023 елның 01 августындагы 74 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләргә классллы чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә аларны саклап калу тәртибе» 4 бүлегендә карарга кушымталар:

- 4.6 пунктындагы 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 4.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә классллы чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән классллы чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Яңа Кәшер ав., Тавабилов ур., 153, Бикасаз ав., Мәктәп ур., 1А, йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Кәшер
авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гиниятуллина